КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 2 сентябрь г.Казань № 770

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәгълүмат технологияләре өлкәсендә укытуга грантлар бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 14 август, 598 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәгълүмат технологияләре өлкәсендә укытуга грантлар бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 14 август, 598 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 1 сентябрь, 607 нче; 2017 ел, 26 июль, 516 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «2020» саннарын «2021» саннарына алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Мәгълүмат технологияләре өлкәсендә укытуга грантлар бирү тәртибендә:

1.1 нче пунктта «һөнәри», «Гамәли информатика» яки» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2 нче пунктта «2020» саннарын «2021» саннарына алыштырырга;

2.1 нче пунктта «Гамәли информатика» яки» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.4 нче пунктта «Гамәли информатика» яки» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.5 нче пунктта «Гамәли информатика» яки» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.4 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Дәгъва итүчеләр түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

агымдагы финанс елында башка хокукый актлар нигезендә бу Тәртипнең 1.1 нче пунктында күрсәтелгән максатларга грант бирү планлаштырыла торган Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмый;

укытуга грант бирү турында шартнамә төзергә планлаштырыла торган ай алдыннан килүче айның 1есенә Татарстан Республикасы бюджетына грантларны, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән грантларны кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты алдында үз вакытында түләнмәгән башка бурычлары булмау;

укытуга грант бирү турында шартнамә төзергә планлаштырыла торган ай алдыннан килүче айның 1есенә Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнар нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмау.»;

түбәндәге эчтәлекле 3.4[1] нче пункт өстәргә:

«3.4[1]. Конкурс нигезендә сайлап алуда катнашу өчен дәгъва итүчеләр конкурс нигезендә сайлап алу турында белдерү бирелгән көннән 12 августка кадәр вәкаләтле органга түбәндәге документларны тапшыра:

бу Тәртипкә теркәлгән кушымтада бирелгән форма буенча грант алуга гариза (алга таба – гариза);

вәкаләтле орган тарафыннан расланган форма буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык;

килешү төзергә планлаштырыла торган ай алдыннан килүче айның 1есенә Татарстан Республикасы бюджетына грантларны, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән грантларны кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты алдында үз вакытында түләнмәгән башка бурычлары булмау турында, шулай ук дәгъва итүченең башка хокукый актлар нигезендә бу Тәртипнең 1.1 нче пунктында күрсәтелгән максатларга грант бирү планлаштырыла торган Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмавы турында гарантия хаты;

салым органыннан укытуга грант бирү турында шартнамә төзергә планлаштырыла торган ай алдыннан килүче айның 1есе хәленә карата Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнар нигезендә түләргә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмауны раслый торган белешмә кәгазе.

Дәгъва итүче гаризага информатика буенча олимпиадаларда, IT-дисциплиналар буенча югары белем бирүче оешмалар арасындагы олимпиадаларда катнашуын раслый торган документлар күчермәләрен (булганда) теркәргә хокуклы.»;

3.5 нче пунктның икенче абзацында «25 августка кадәр» сүзләрен «18 августка кадәр» сүзләренә алыштырырга;

3.9 нчы пунктның икенче абзацында «50 грант» сүзләрен «30 грант» сүзләренә алыштырырга;

3.11 нче пунктның икенче абзацында «86 һәм аннан югарырак» сүзләрен «90 һәм аннан югарырак» сүзләренә алыштырырга;

3.11 нче пунктның өченче абзацында «71дән 86га кадәр» сүзләрен «71дән 90га кадәр» сүзләренә алыштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 3.12[1] нче пункт өстәргә:

«3.12[1]. Дәгъва итүчегә грант бирүдән баш тарту өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

бу Тәртипнең 3.4[1] нче пунктында каралган документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

дәгъва итүче тарафыннан бирелгән һәм бу Тәртипнең 3.4[1] нче пунктында күрсәтелгән гаризадагы һәм документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы;

дәгъва итүченең бу Тәртип таләпләренә туры килмәве.»;

4.1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Конкурс комиссиясе беркетмәсе нигезендә вәкаләтле орган, агымдагы елның 1 октябреннән дә соңга калмыйча, грант алучы һәм Университет белән Хезмәттәшлек итү турындагы килешү нигезендә вәкаләтле орган раслый торган форма буенча укытуга грант бирү турында өч яклы килешү төзи.

Укытуга грант бирү турындагы шартнамәдә түбәндәгеләр карала:

грант алучының Татарстан Республикасы территориясендә грант буенча белем алу вакытына тигез булган чор дәвамында белем алу тәмамланган вакыттан мәгълүмат-коммуникация технологияләре өлкәсендә хезмәт эшчәнлеген, шул исәптән законнар белән билгеләнгән тәртиптә үзмәшгуль зат буларак хезмәт эшчәнлеген (алга таба – эшләп түләү) гамәлгә ашыруга йөкләмәсе. Әгәр дә грант алучы әлеге хезмәт эшчәнлеген Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнарында яки аның ведомство буйсынуындагы оешмаларда гамәлгә ашырса, эшләп түләү вакыты ике тапкырга кыскара. Эшләп түләү вакытына йөклелек һәм бала табу буенча ял, өч яшькә кадәр бала карау буенча ял, Университетта магистратура программасын үзләштерү һәм грант алучының хәрби хезмәткә чакыру чоры кертелми;

грант алучының уку өчен акчаны Университет счетына күчерү юлы белән грант алуга ризалыгы;

грант алучының вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының грант алучы тарафыннан грант бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүләр үткәрүгә ризалыгы;

грант алучының эшләп түләү чорында Россия Федерациясе Пенсия фондына иминият кертемнәре күчерүләрне түләү турында белешмә кәгазе бирү буенча йөкләмәсе.»;

4.2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Грант вәкаләтле орган тарафыннан грант алучының укуы өчен Университетның Россия кредит оешмасында ачылган счетына акча күчерү юлы белән укытуга грант бирү турындагы шартнамә төзелгән көннән 10 көн эчендә грант алучыга бирелә.»;

4.6 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.6. Вәкаләтле орган грант алучының уку өчен вәкаләтле орган тарафыннан фактта күчерелгән акчаны Татарстан Республикасы бюджетына түбәндәге очракларда кире кайтаруы турында карар кабул итә:

бу Тәртипнең 4.3 нче пунктындагы икенче, өченче, җиденче һәм сигезенче абзацларында күрсәтелгән очракларда;

грант алучының эшләп түләү буенча йөкләмәләрен үтәмәгәндә;

грант алучы тарафыннан вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган грант бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе бозылганда.

Вәкаләтле орган, әлеге карар кабул ителгән көннән биш эш көненнән дә соңга калмыйча, бу турыда грант алучыга язма рәвештә хәбәр итә.»;

5 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 5.2 нче пункт өстәргә:

«5.2. Грант алучының югары белем бирүче мәгариф программасын үзләштерүе, югары белем алуы һәм эшләп түләүне гамәлгә ашыруы грант бирүнең нәтиҗәсе булып тора.»;

Мәгълүмат технологияләре өлкәсендә укытуга грантлар бирү тәртибенә теркәлгән кушымтада:

«Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасының мәгълүматлаштыру һәм элемтә министры Р.А.Шәйхетдиновка» сүзләрен «Татарстан Республикасының мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрына» сүзләренә алыштырырга;

«тору урыны адресы» сүзләрен «теркәлү адресы» сүзләренә алыштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин